РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.03.2024 Буа шәһәре № 51 Бк/к

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Ситуация үзәген төзү
турында» Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 14 апрелендәге 123/Бк/к номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарында, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасының бүленгән ситуация үзәгенә керүче оешмаларда эшләүче ситуация үзәкләрен функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэмин итүгә типовой таләпләр стандарты һәм Татарстан Республикасы бүленгән ситуация үзәгенә керүче ситуация үзәкләрен аккредитацияләү турында нигезләмәләрне раслау турында» 2018 елның 02 октябрендәге 894 номерлы карары нигезендә Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ситуация үзәген төзү турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 апрелендәге 123/Бк/к номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ситуация үзәген төзү һәм эшләве өчен, шулай ук башлангыч мәгълүматлар җыю һәм муниципаль дәрәҗәгә таркатылган Россия Федерациясе субъектларының югары вазифалы затлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен мониторинглау өчен җаваплылык үзәге итеп ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын билгеләргә .»;

4 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә Буа муниципаль районы Ситуация үзәге администраторы вәкаләтләрен бирергә.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматны саклау бүлеге башлыгына мәгълүматны саклауны тәэмин итү һәм кулланучыларның Ситуацион үзәкнең мәгълүмати ресурсларына керүләрен оештыру бурычларын йөкләргә.

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ситуация үзәген төзү турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 14 апрелендәге 123/Бк/к номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ситуация үзәге турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.3 пункты. үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«2.3. Буа муниципаль районы Башлыгы, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, аның профильле бүлекчәләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, Татарстан Республикасы Башлыгы Аппаратлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты сораулары буенча мәгълүмати, мәгълүмати-белешмә һәм мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү.

Татарстан Республикасы Конституциясендә тарихи, милли һәм башка традицияләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы югары вазыйфаи заты вазыйфасының өстәмә атамасы каралырга мөмкин, ул Федераль закон белән беркетелгән атамадан соң Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында күрсәтелергә мөмкин. Мондый атамада дәүләт башлыгы Россия Федерациясе Президенты вазифасының атамасын тәшкил итүче сүзләр һәм сүзтезмәләр булырга тиеш түгел.».

4.2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«4.2. Мәгълүматны саклау буенча эшләрне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматны саклау бүлеге башлыгы башкара.».

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов